2018 елга Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы гомуми
белем бирү оешмаларының норматив
чыгымнарын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2018 елга Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга беркетелгән норматив чыгымнарны расларга.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының финанс-бюджет палатасына түбәндәгеләр раслаган мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә:

«2018 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 2017 елның 22 сентябрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән;

әлеге карарның 1 пункты белән.

3. Әлеге карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Е. А. Тарнавскийга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы А.С. Полюшков

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның "__"______________ ____ номерлы карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга**
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре<br>. | Территориаль дислокация | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елына сум |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | авыл җирлеге | 88 242 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | авыл җирлеге | 136 695 |

Эшләр идарәчесе: Д.Р. Сабирзянова